# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2023 елның 21 октябреннән № 2

Татарстан Республикасы Азнакай
муниципаль районы Агерҗе авыл
җирлегенең Агерҗе авылында 2024
елда гражданнарның үзара салымын
кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Агерҗе авыл җирлегенең Агерҗе Авылы торак пунктында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Агерҗе авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, өлешчә мобилизация буенча чакырылган 1,2,3 төркем инвалидлардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 600 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Агерҗе авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (г.Гафиятуллин урамы буенча килешү буенча эшләр өчен түләү).

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен:

- "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталы" веб-адресы буенча: http://pravo.tatarstan.ru;

-Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: http//aznakayevo. tatar. ru

- ТР, Азнакай муниципаль районы, Агерҗе авылы, Г.Әхмәтова урамы, 14А йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында; Агерҗе авылы, С. Хәким урамы, Агерҗе авылы, Г. Гафиятуллин урамы киселешендә, 10 һәм 23А номерлы йортлар арасында кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Агерҗе авыл җирлеге башлыгы
Азнакай муниципаль районы Н. Н. Хәсәнов